Алабирде

# ЯЗДАН АЕРЫП БУЛМЫЙ ТУКАЙНЫ!

Әлфия ЗАҺИДУЛЛИНА.

*Яздан аерып булмый*
*Тукайны!*
*Язда килгән, язда янган ул.*
*Язы, киләчәге барлар ничек*
*китсен,*
*Ничек югала алсын дөньядан.*

*Кемнәр көтми ышанулар,*
*гөлләр,*
*Яшәүләр биргән бу айны?*
*Яздан, гаделлектән,*
*киләчәктән*
*Мөмкин түгел аеру Тукайны!*
Равил ФӘЙЗУЛЛИН.

1913 елның апреле ераклашкан саен Тукай безгә тагын да якыная, аның шәхесе, тарихтагы урыны тагын да олырак, мәһабәтрәк булып күренә. Бу дөньяда бары 27 ел яшәп, халык җанына әверелгән Тукай рухы – бүген дә безне иманга, туган телгә, әдәп-әхлакка, хезмәткә өнди. Аның үлемсез иҗаты, вакыт сынавына бирешмичә, һаман сокландыра, уйландыра. Сабыйлардан алып, чал гасыр тиңдәшләренә кадәр аның әсәрләрен үз итәләр, ярataлар. Без дә яратабыз...

Без дигәнем, Алабирде урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм укучылары. "Мәгариф" журналының февраль санында "Без – Тукайлы халык" әдәби викторина сорауларына җаваплар әзерләп җибәргән идек һәм 9 апрельдә "Тукай җыены"на чакыру алдык. 22 апрельдә 5нче сыйныф укучысы Алия Галиева (рәсемдә) белән юлга чыктык.

Башкалабызга килгәч, башта Таһир Сабирҗанов, Марсель Әхмәтҗанов җитәкчелегендә Казандагы Тукай эзләре буйлап җәяүле сәяхәттә катнаштык. Анда галимнәр Тукай белән бәйле биналарның бер-бер артлы юкка чыгуы турында ачынып сөйләделәр.



Шуннан соң 12нче кызлар гимназиясендә "Тукай һәм милләт язмышы" дигән темага "Түгәрәк өстәл" артында сөйләшү узды, аны "Мәгариф" журналының баш мөхәррире Габделхак Шәмсетдинов ачып җибәрде. Җыенда Тукай рухына дога укылды. Авылдашыбыз Ильяс хәзрәт Җиһаншин һәм Вәлиулла хәзрәт бүләкләр тапшырдылар. Чөнки әлеге викторина Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә оештырылган иде. Без, Кырлай мәктәбе укучыларыннан кала, икенче булып Дипломга һәм "Мәгариф" журналының "Иң яшь Тукай варисы" дигән мактаулы исемгә лаек булдык, китаплар белән бүләкләндек. Түгәрәк өстәл артында депутатыбыз Туфан Миңнуллин, шагыйрь һәм композитор Фердинант Гайсин, Лениногорскидан язучы Җәмит Рәхимовның җәмагате Галия апа, Тәэмина апа Биктимероваларның чыгышлары гимназия кызларының Тукай иҗатыннан алынган әсәрләре белән үрелеп барды. Бәйрәм шагыйрь музеенда оештырылган "Тукай укулары" белән йомгакланды.

Тукай туган көн, чыннан да, зур бәйрәм. Үзенең үлемсезлеген сизгәндәй, бөек эшләренең һичбер вакытта югалмаячагын белгәндәй Тукай мондый юллар язып калдырган:

*Ашкынамын мин әбәд бетмәс*
*урынга, мәңгегә,*
*Мәңгелеккә – мәңге рухлы,*
*мәңге нурлы ямьлегә!*
*Мин анда мәңге көләч һәм*
*мәңге яшь булмак телим,*
*Бу кояш сүнсен, җиренә мин*
*кояш булмак телим.*

Шагыйрьнең теләге тулысынча тормышка ашкан. Аның гуманлы поэзиясе, халыкның батырлыгына, хезмәт сөючәнлегенә һәм әхлакый сафлыгына дан җырлаган әсәрләре чын мәгънәсендә халык байлыгына әверелде. Аның даны киләчәккә атлавын дәвам итә.